ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 25.05.2022 г. Казань № 55-7/тэ-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләрне (тарифларны) җайга салу кагыйдәләренең 6 пункты, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2022 елның 25 маендагы 12-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2020-2024 елларга тарифлар билгеләү турында» 13.12.2019 № 5-114/тэ;

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте күрсәтә торган җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-114/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 09.12.2020 № 359-57/тэ-2020;

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте күрсәтә торган җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-114/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 07.12.2021 № 456-96/тэ-2021.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина